
# Т. Миңнуллин "Әниләр һәм бәбиләр" драмасы



# «Әниләр һәм бәбиләр» драмасында конфликт һәм проблемалар

- Туфан Миңнуллин драматургиясе соңгы елларда заманга тирәнрәк үтеп  керә, зур – зур фикерләр күтәрә. Анда бүгенге яшәешнең, агымдагы тормышның өлгергән мәсьәләләре, төрле яклары чагыла. Шул исәптән үкенечле, гыйбрәтле яклары да. Шуны автор «Әниләр һәм бәбиләр» (1984) драмасында да раслый. Кешегә, табигатьнең барлык җан ияләрендәге кебек, үзен саклап калу, алга таба үрчү инстинкты салынган. Ата – ана үз баласы өчен һәммәсен эшли, авырлыкларга түзә, хәтта үлемгә дә бара. Ләкин кешелек тәрәккый иткән, ә әхлак кануннары йомшарган саен бу изге бурычка хыянәт итү очраклары ешая.




**Тормышның хәрәкәте төрле капма – каршы күренешләрнең каршылыклы тенденцияләрнең, характерларның көрәше рәвешендә бара. Конфликтлар булмаган җирдә чын тормыш та, алга үсеш тә юк. Тормыштагы каршылыклар әсәрнең сюжетында да чагылыш таба.**

**Сюжет нигезендә дә хәрәкәт ята. Характерлар исә вакыйгалар эчендә генә ачыла.**

**Драма әсәрендә сюжет мөһим роль уйный. Сюжет ул кешенең характерлары һәм язмышлары ачыла торган вакыйгалар агышы, системасы дигән сүз.**

**«Әниләр һәм бәбиләр» драмасында да шул күзәтелә. Драмада сюжет элементларының барысы да табыла.**




“Әниләр һәм бәбиләр” драмасы 1983нче елны язылa. Чын мәгънәдә шул еллардагы татар хатын-кызларына хас булмаган бала проблемалары теләсә кайссы укучыны аптырашта калдыра.
Әйтергә кирәк, Алтынчәчнең бүлеп – бүлеп бирелгән монологында автор позициясе бирелә: «Бала шаяра торган нәрсә түгел», ана булу – зур бәхет. Ул, нигездә, әсәрнең төп идеясе белән тәңгәл килә.

Әсәрдә зур конфликт бар: заман һәм аналар арасында. Кемдер бала табасы килеп тә таба алмый, ә кемдер бала табу бәхетенә ирешеп тә, эгоистлыгы аркасында һәм заман кууы нигезендә, аннан баш тарта.

Димәк, монда яшь бала халык традицияләрен дәвам итәргә алынучы яңа буын вәкиле итеп бирелә. Әби – баба һәм әти - әни исә әлеге традицияләрне бүгенге көннәргә алып килгән буыннар. Нәкъ менә шушы буыннар арасында драматургик каршылык, характерлар бәрелеше – асылда традицияләрнең диалектик яшәеше, пьесаларның конфликты булып тора. Әлеге пьесаның персонажларын бер үзәк мотив берләштерә - традицияләргә мөнәсәбәт мәсьәләсе.

- 
- Әйтергә кирәк, Алтынчәчнең бүлеп – бүлеп бирелгән монологында автор позициясе бирелә: «Бала шаяра торган нәрсә түгел», ана булу – зур бәхет. Ул, нигездә, әсәрнең төп идеясе белән тәңгәл килә.
- Әсәрдә зур конфликт бар: заман һәм аналар арасында. Кемдер бала табасы килеп тә таба алмый, ә кемдер бала табу бәхетенә ирешеп тә, эгоистлыгы аркасында һәм заман кууы нигезендә, аннан баш тарта.
- Димәк, монда яшь бала халык традицияләрен дәвам итәргә алынучы яңа буын вәкиле итеп бирелә. Әби – баба һәм әти - әни исә әлеге традицияләрне бүгенге көннәргә алып килгән буыннар. Нәкъ менә шушы буыннар арасында драматургик каршылык, характерлар бәрелеше – асылда традицияләрнең диалектик яшәеше, пьесаларның конфликты булып тора. Әлеге пьесаның персонажларын бер үзәк мотив берләштерә - традицияләргә мөнәсәбәт мәсьәләсе.
- 

Игътибарыгыз өчен рәхмәт)